| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ БАВЛИНСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

08.04.2026 Баулы шәһәре №42

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлегенең генераль планы турында» карарының үз көчен югалтуын тану турында

«Шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары арасында вәкаләтләрне яңадан бүлү турында», Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2026 елның 28 февралендәге 377/О номерлы боерыгы белән, «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Исергәп авыл җирлегенең генераль планын раслау турында» 2023 елның 23 декабрендәге 131-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Баулы муниципаль район Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Баулы муниципаль район Советының түбәндәге карарларының үз көчләрен югалтуын танырга:

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлегенең генераль планы турында» 2020 елның 29 июлендәге 270 номерлы карарын;

- «Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының Исергәп авыл җирлегенең генераль планына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 26 декабрендәге 156 номерлы карарын.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының pravo.tatarstan.ru адресы буенча рәсми порталында һәм Баулы муниципаль районының bavly.tatarstan.ru адресы буенча рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

Баулы муниципаль районы Башлыгы,
район Советы рәисе И.И. Гозәеров